КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 июль г.Казань № 835

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинетының кайбер карарларына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында каты коммуналь калдыклар белән эш итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2017 ел, 6 июль, 460 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 17 июль, 577 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1122 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1171 нче; 2020 ел, 1 июнь, 453 нче; 2020 ел, 22 декабрь, 1174 нче; 2022 ел, 21 ноябрь, 1246 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында каты коммуналь калдыклар белән эш итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәдә:

6 пунктта:

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында каты коммуналь калдыклар белән эш итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем составында:

ведомствоара эшче төркем составыннан М.Н.Садыковны, Л.З.Хәйретдиноваы чыгарырга;

ведомствоара эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының калдыклар белән эш итү бүлеге төп консультанты Ирина Викторовна Козинаны;

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры Марсель Мансур улы Миңнуллинны;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының калдыклар белән эш итү бүлеге төп консультанты Зарина Нургаяз кызы Хафизованы;

Олег Олегович Суздальцевның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Альтернатив генерацияләү компаниясе – 2» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең финанс директоры (килешү буенча)».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының җитештерү һәм куллану калдыкларының төбәк кадастрын алып бару тәртибен раслау турында» 2017 ел, 17 август, 589 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының җитештерү һәм куллану калдыкларының төбәк кадастрын алып бару тәртибенә, 1.4 пункттагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарын» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарын» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схеманы раслау турында» 2018 ел, 13 март, 149 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 14 май, 391 нче; 2020 ел, 21 май, 414 нче; 2021 ел, 19 октябрь, 985 нче; 2022 ел, 9 июль, 661 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1465 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схемага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 бүлектә:

5.2 нче таблицадан соңгы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2025 елларга дәүләт хакимиятенең республика органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре эшчәнлеге эффективлыгын һәм халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторларын раслау турында» 2023 ел, 31 март, 385 нче карарында 5.3 нче таблицадагы «Җитештерү һәм куллану процессында барлыкка килгән калдыкларның гомуми күләмендә файдаланылган, зарарсызландырылган калдыклар өлеше, процент» индикаторының зурлыгы билгеләнде.»;

5.3 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3 нче таблица

«Җитештерү һәм куллану процессында барлыкка килгән калдыкларның гомуми күләмендә файдаланылган, зарарсызландырылган калдыклар өлеше, процент» күрсәткеченең (индикаторының) зурлыклары турында мәгълүмат

| 2021 ел (факт) | 2024 ел (бәяләү) | Чиге | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 ел | | | | 2024 ел | 2025 ел |
| | | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | | |
| Җитештерү һәм куллану процессында барлыкка килгән калдыкларның гомуми күләмендә файдаланылган, зарарсызландырылган калдыклар өлеше, процент | | | | | | | |
| 61,9 | 51,0 | × | × | × | 51,0 | 51,0 | 51,0»; |

9 бүлекнең 9.3.4 бүлекчәсендә:

җиденче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

10 бүлекнең 10.2.5 бүлекчәсендәге кырык беренче абзацында «Техник җайга салу һәм метрология федераль агентлыгының «Калдыкларны утильләштерү һәм зарарсызландыру (термик ысул белән зарарсызландырудан башка (калдыкларны яндыру)» мәгълүмат бирү характерындагы техник белешмәлегеннән (МТБ 15-2016, Мәскәү, Иң яхшы уңайлы технологияләр бюросы, 2016)» сүзләрен «Техник җайга салу һәм метрология федераль агентлыгының «Калдыкларны утильләштерү һәм зарарсызландыру (термик ысуллардан башка)» мәгълүмат бирү характерындагы техник белешмәлегеннән (МТБ 15-2021, Мәскәү, Иң яхшы уңайлы технологияләр бюросы, 2021)» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибен раслау турында» 2018 ел, 21 декабрь, 1202 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 16 июль, 589 нчы; 2020 ел, 26 ноябрь, 1066 нчы; 2021 ел, 13 март, 130 нчы; 2022 ел, 14 апрель, 353 нче; 2023 ел, 2 март, 199 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибенә, 1.5 пунктның бишенче абзацындагы «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин